РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_04_» ___02___ 2026 ел №93

2026 елның I кварталына
Ютазы муниципаль районы буенча
1 квадрат метр торак мәйданының
уртача базар бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге №31-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен гражданнарны исәпкә кую һәм мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарга торак биналарда, муниципаль торак фондының торак урыннары социаль наем шартнамәләре буенча торак бирү максатларында исәпкә алу тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р  б и р ә:

1. Ютазы муниципаль районында «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан 1 квадрат метр торак бинаның уртача бәясен билгеләү буенча тикшеренү нәтиҗәләре буенча, 2026 елның I кварталына Ютазы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативын – 53 571 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2014 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244

санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
8(85593)2-42-05